СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 149 13.06.2017

№ ________ от _________________

# КАРАР

ТР Саба муниципаль районы Советының 2011 елның 26 августындагы 55нче карары белән расланган ТР Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 01 маендагы 90-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә һәм Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының федераль закон таләпләрен бозуларны бетерү турындагы тәкъдименә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 26 августындагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (ә 2012 елның 27 февралендәге 99 номерлы, 2012 елның 26 апрелендәге 118 номерлы, 2013 елның 29 апрелендәге 193 номерлы, 2016 елның 25 февралендәге 36 номерлы Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 22.4 пунктта «15» санын «10» санына алмаштырырга;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 22.8 пункт өстәргә: «22.8. Хезмәт көне нормалаштырылмаган муниципаль хезмәткәргә өч календарь көн дәвамында хезмәт көне нормалаштырылмаган өчен ел саен өстәмә түләүле отпуск бирелә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов